| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 02 нче сентябре Олы Кайбыч авылы № 13

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында»гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында»гы Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 елның 26 июлендәге 251 – ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 40 статьясына һәм «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы Федераль законның 13.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2019 елның 26 июлендәге 228 – ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 августындагы 17 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында»гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның 8 пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдимнәр өстәргә:

«Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкаручы зат әлеге мәгълүматларны депутат булып сайланган көннән соң дүрт ай эчендә, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру туктатылганнан соң, шулай ук хисап чоры дәвамында белешмәләр (хисап чоры) биргән һәр ел өчен, хисап чоры дәвамында килешүләр эшләгән очракта тапшыра «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»гы 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган. Хисап чоры дәвамында мондый килешүләр башкарылмаган очракта, күрсәтелгән зат бу хакта Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи

затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) хәбәр итә.»;

11 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

«2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматны бозу бик ук мөхим булмаган очракта, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) Кисәтмә;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) вәкаләтләре беткәнче даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://bkaybic-kaybici.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге башлыгы А.И. Рәхмәтуллин